**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2019 Балык Бистәсе штп. № 181пи

Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының, үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының 2019 елның 18 апрелендәге "Җирлекләр һәм ҮБ ларның бухгалтерлар хезмәтенә түләү шартларының үзгәреше турында" 03-16/2920 номерлы хаты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2019 елның 1 апреленнән үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләүнең яңа системасы кертелү уңаеннан КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга (теркәләләр):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәне.

2.Хезмәткәрләрнең әлеге карар белән билгеләнә торган хезмәт хакларының күләме хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләренең зурлыгы һәм алар тарафыннан шул ук квалификациядәге эшләр башкарылу сакланганда аларга 2019 елның 31 мартына кадәр түләнгән хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көчен керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ногманова И.М.га:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренең һәм муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары вазыйфаларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) исемнәрен (аталышларын) әлеге карар белән тәңгәллеккә китерүне тәэмин итәргә;

карарның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашырырга.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 27 маендагы 181 пи
номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында**
**Нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен тәртипкә сала һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренең эш хакы вазыйфаи хезмәт хакыннан, вазыйфаи хезмәт хакына тиешле еллар эшләнгән өчен (за выслугу лет) айлык өстәмә, эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм ел саен бирелә торган түләүле ял алдыннан бер тапкыр бирелүче түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хакы (оклад) түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Үзидарәлек учреждениесе булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Үзидарәлек учреждениесе җитәкчесе | 23 700 | |
| Үзидарәлек учреждениесе | 21 500 | |

| | | |
|---|---|---|
| җитәкчесе урынбасары | | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 21 500 |
| Бүлек башлыгы | 17 700 | 17 700 |
| Әйдәүче бухгалтер | 15 300 | 15 300 |
| Бухгалтер | 14 000 | 14 000 |

Үзидарәлек (муниципаль) учреждениесе булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертүнең шарты булып структурасында һәркайсында 5 берәмлектән ким булмаган штат саны белән 3 тән ким булмаган бүлекнең булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә 5 берәмлектән ким булмаган штат саны булырга тиешле.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренә гамәлгә кертелә:

1)түбәндәге күләмнәрдә вазыйфаи хезмәт хакына тиешле еллар эшләнгән өчен айлык өстәмә:

| Эш стажы (булганда) | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1 дән 5 елга хәтле | 5 |
| 5 тән 10 елга хәтле | 7 |
| 10 нан 15 елга хәтле | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә вазыйфаи хезмәт хакының 10%ы күләмендә;

3)айлык вазыйфаи хезмәт хакының ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) ел саен бирелүче түләүле ял алганда вазыйфаи окладның 120 % ы күләмендә елга бер бирелә торган түләү.

Календарь ел дәвамында хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле ял бирелмәгән очракта елга бер тапкыр бирелә торган түләү исәпләнә һәм декабрь аенда эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңармыйча.

Хезмәткәргә елга бер тапкыр бирелә торган түләү беренче елын эшләүчегә ел саен бирелә торган түләүле ял бирелгәндә календарь елда эшләнелгән вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнә. Эшләгән вакыты эшкә кергән көненнән календарь елның 31 декабрен кертеп исәпләнелә.

5) эш нәтиҗәләре буенча премия расланган хезмәткә түләү фонды чикләрендә (премия күләме хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып тәгаенләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

6) акчалата бүләкләү, матди ярдәм – расланган хезмәткә түләү фонды чикләрендә);

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренә хезмәткә түләүнең еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \text{Р} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ – җитәкчеләр һәм белгечләр хезмәтенә түләүнең еллык фонды;

$O_d$ – җитәкчегә һәм белгечкә айлык вазыйфаи оклад түләүгә средстволар суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгәнгә вазыйфаи окладка айлык өстәмә, эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә, акчалата бүләкләүгә, ел саен бирелүче түләүле ял алганда елга бер бирелә торган түләүгә, матди ярдәмгә средстволар суммасы;

Р – җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының 5 пунктчасы белән билгеләнгән шартлардан чыгып тәгаенләнә торган);*

$n$– җитәкчеләр һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт хакы буенча түләүләргә исәпләүләр.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 27 маендагы 181 пи
номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмә**

1. Татарстан Республикас муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен тәртипкә сала һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары (окладлары) күләмен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи хезмәт хакыннан (окладтан), вазыйфаи хезмәт хакына тиешле еллар эшләнгән өчен (за выслугу лет) айлык өстәмә, эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм ел саен бирелә торган түләүле ял алдыннан бер тапкыр бирелүче түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш бухгалтер | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Бухгалтер | - | 14 500 сум |

Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасы кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының 3,5 меңнән артык булуы тора.

4. Бухгалтерларга билгеләнә:

1) )түбәндәге күләмнәрдә вазыйфаи хезмәт хакына тиешле еллар эшләнгән өчен айлык өстәмә:

| Эш стажы (булганда) | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга хәтле | 5 |
| 5 елдан 10 елга хәтле | 7 |
| 10 елдан 15 елга хәтле | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә вазыйфаи хезмәт хакының 10%ы күләмендә;

3)айлык вазыйфаи хезмәт хакының ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) ел саен бирелүче түләүле ял алганда вазыйфаи окладның 120 % ы күләмендә елга бер бирелә торган түләү.

Календарь ел дәвамында хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле ял бирелмәгән очракта елга бер тапкыр бирелә торган түләү исәпләнә һәм декабрь аенда эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңармыйча.

Хезмәткәргә елга бер тапкыр бирелә торган түләү беренче елын эшләүчегә ел саен бирелә торган түләүле ял бирелгәндә календарь елда эшләнелгән вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнә. Эшләгән вакыты эшкә кергән көненнән календарь елның 31 декабрен кертеп исәпләнелә.

5) эш нәтиҗәләре буенча премия расланган хезмәткә түләү фонды чикләрендә (премия күләме хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып тәгаенләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

6) акчалата бүләкләү, матди ярдәм – расланган хезмәткә түләү фонды чикләрендә);

5.Бухгалтерларның хезмәт хакының еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \text{Р} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ – бухгалтерлар хезмәт хакының еллык фонды;

$O_d$ – бухгалтерга айлык вазыйфаи оклад түләүгә средстволар суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгәнгә вазыйфаи окладка айлык өстәмә, эшнең киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә, акчалата бүләкләүгә, ел саен бирелүче түләүле ял алганда елга бер бирелә торган түләүгә, матди ярдәмгә средстволар суммасы;

Р – бухгалтерларның еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының 5 пунктчасы белән билгеләнгән шартлардан чыгып тәгаенләнә торган);*

$n$– бухгалтерларның штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт хакы буенча түләүләргә исәпләүләр.